ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2022 г. Казань № 40-7/кс-2022

«Коммунсервис-Актаныш» җитештерү берләшмәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызуга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 13 апрелендәге 8-ПР номерлы Идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны хәл итүче «Коммунсервис – Актаныш» җитештерү берләшмәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Коммунсервис – Актаныш» ҖБ ҖЧҖ) өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Коммунсервис – Актаныш» ҖБ ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6

номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.04.2022 № 40-7/кс-2022
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Коммунсервис – Актаныш» ЖБ ҖЧҖ өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 13.04.2022 № 40-7/кс-2022 карар үз көченә кергән көннән башлап 2022 елның 30 июненә кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 13.04.2022 № 40-7/кс-2022 карар үз көченә кергән көннән башлап 2022 елның 30 июненә кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр |
| | Актаныш муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Коммунсервис – Актаныш» ЖБ ҖЧҖ* | 36,12 | 36,12 | 23,81 | 23,94 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге